М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов

# Туган тел
## (ТАТАР ТЕЛЕ)

### 3 сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

*Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен*

КАЗАН
2020

УДК 811.512.145 (075.2)
ББК 81.632.3я71
Ш92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

**Шәкүрова, М. М.**

Ш92 Туган тел (татар теле). 3 сыйныф. Методик әсбап : башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен. / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. — Казан, 2020. — 32 б.

Методик әсбапта уку предметының эчтәлеге бирелә, дәреслек белән эшләү тәртибе аңлатыла. Тематик планда ике юнәлеш өчен булган лексик, грамматик материал, укучыларның эшчәнлек төрләре, аларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә куелган таләпләр карала, дәрес планы үрнәкләре бирелә.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Г. Ибрагимов исем. ТӘһСИ, 2020
© М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов, 2020

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Укыту-методик комплекты татар телен туган тел буларак өйрәнә торган 3 сыйныф укучылары белән эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә. УМК үз эченә уку әсбабы, электрон дәреслек, аудиоязмалар дискы һәм укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында «Туган тел (татар теле)» предметы Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китерелеп укытыла. Туган тел (татар теле) предметыннан белем бирүнең сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уяту һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга, язарга, фикерләргә өйрәтү таләп ителә.

3 сыйныфта «Туган тел (татар теле)» предметын укыту түбәндәге максатларны тормышка ашыруга юнәлтелә:

- укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру, сөйләм мөмкинлекләреннән чыгып, телдән һәм язмача аралашырга өйрәтү;
- балалар әдәбиятын, тарихын, фольклор әсәрләрен өйрәнү аша татар мәдәниятенә карата ихтирам хисләре тәрбияләү.

Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган бурычлар:

- Татарстан Республикасында төрле милләтләр өчен аралашу чарасы буларак татар теле турында мәгълүмат бирү;
- сөйләмә һәм язма телне үстерү максаты белән телнең грамматик нигезләрен үзләштерү;
- тел материалын үзләштерү барышында, аралашу очракларында, рольле уеннарда укучының шәхси сыйфатларын, игътибарын, фикерләү сәләтен, хәтерен һәм иҗадилыгын үстерү;
- предметка карата кызыксыну, уңай мотивация, туган телне өйрәнүгә мөмкинлек бирә торган махсус универсаль уку гамәлләре формалаштыру.

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

### Уку әсбабының структурасы

Уку әсбабы ике кисәктән тора. Һәр кисәк ике зур теманы үз эченә ала. Беренче кисәктә «Мин» һәм «Тирә-як, көнкүреш» темалары, икенче кисәктә «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» темалары урнаштырылды.

### Темаларның төзелеше

Һәр тема бертөрле калыпка салынды. Темалар икедән алып бишкә кадәр дәресне үз эченә ала.

1) Укучылар ярдәме белән тема әйтелә, дәреснең максаты, бурычлары формалаштырыла.
2) Грамматик материал өйрәнелә.
3) Яңа теманы ныгыту өчен биремнәр эшләнә. Шулар арасында мәҗбүри рәвештә халык авыз иҗаты үрнәкләре белән бәйле эш тәкъдим ителә.
4) Парларда эш башкарыла.
5) Укучылар ярдәме белән Куян күчтәнәчендә бирeләчәк тема билгеләнә. Темага керү өчен, бирем эшләнә.
6) Яңа тема аңлатыла (Куян күчтәнәче).
7) Куян күчтәнәчен ныгыту өчен, биремнәр башкарыла.
8) Теманы йомгаклау өчен күнегүләр, логик биремнәр, кызыклы эш төрләре бирелә.

Уку әсбабы ике юнәлешне (база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне) үз эченә ала. Туган телне тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган материал зәңгәрсу фон белән биреледе. Әмма база өлешен өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар, балаларның белем дәрәҗәләреннән, мөмкинлекләреннән чыгып, әлеге биремнәрне дә тәгъдим итә алалар. Ике юнәлешнең бер китапта бирелүе көчлерәк укучылар белән аерым якын килеп эшләү мөмкинлеге тудыра.

## Уку әсбабындагы күнегү төрләре

*«Рольләргә бүлеп укы»* биреме ике юнәлеш өчен булган материалны берләштерә. База өлешен өйрәнүчеләргә дәресләр геройлар әңгәмәсе формасында тәкъдим ителә. Геройлар санына карап, репликалар төсле рамкаларда бирелә. Бу укучыга үз роленә караган сүзләрне күрергә уңайлы итеп эшләнгән. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган диалог, гадәттәгечә, зәңгәрсу фон эченә урнаштырылды.







Уку әсбабында төрле логик биремнәр бар. Бу күнегү ахырында тәкъдим ителгән сорау да, аерым күнегү дә булырга мөмкин. Мәсәлән, укучыларга *Бер агачтан ничә китап ясап була дип уйлыйсың?* (40 бит, 2 кисәк) соравына җавап бирергә кушыла. Укытучы бер агачтан 18000 бит кәгазь ясап булуын өстәп әйтә ала. Укучылар белән бергәләп, бит саны төрле булган китапны әзерләү өчен, ничә агач кирәк булуы исәпләп чыгарыла. Агачларны, табигатьне саклау турында әңгәмә корыла.

Хәрефләрдән, иҗекләрдән төрле сүзләр төзү кебек күнегүләр укучыларны дөрес язарга өйрәтә.

**2. Хәрефләрдән елга исемнәре төзе.**




**6. Иҗекләрдән сүзләр ясап әйт.**




Мәкаль, әйтемнәр белән эшләү өчен дә төрле биремнәр тәкъдим ителә.

**20. Мәкальләрнең башы белән ахырын парлап әйт.** Антоним сүзләрне тап.

Аз сөйлә,

искесен сүтмә.

унҗан кеше — алтын кеше.

Яңа ой салмыйча,

Ялкау кеше — ярты кеше,

күп эшлә.

Беренче сыйныфтан бирле даими рәвештә алып барыла торган җөмлә калыплары белән эшләү алымы 3 сыйныф уку әсбабында

да урын алды. Бу укучыларны дөрес итеп җөмлә төзергә өйрәтә, җөмләдә сүз тәртибен истә калдырырга ярдәм итә.




Уку әсбабында төрле грамматик категорияләр (исем сүз төркеменең килеш белән төрләнүе, зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнүе, фигыльнең зат-сан белән төрләнүе һ.б.) җөмләләр ярдәмендә аңлатыла. Бу рәвешле аңлату күпкә отышлы, бала һәр кушымчаны аңлап куллана.






- Фигыльләрне тиешле зат-санда яз.

| | | |
|---|---|---|
| трамвайга утырам | мин | автобустан ________ |
| трамвайга ________ | син | автобустан ________ |
| трамвайга ________ | ул | автобустан төшә |
| трамвайга утырабыз | без | автобустан ________ |
| трамвайга ________ | сез | автобустан ________ |
| трамвайга ________ | алар | автобустан төшәләр |

Матур, дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү максатыннан, язма хәрефләр белән бирелгән күнегүләр дә бар. Өченче сыйныфта мондый төр эш катлауландырыла, өстәмә бирем башкару сорала.

- Җөмләләрне тулыландыр.

*1) Минем яңа ________ , ________ , ________ бар. 2) Ятим малайның исеме – ________ . 3) Нури ________ ________ кигән. 4) Без ________ уйнадык. 5) Нури ________ килде.*

Өйрәнгән темаларны кабатлау өчен, уку әсбабында «Текст белән эш» һәм «Кабатлау» дәресләре бар.

«Текст белән эш» дәресендә укучылар аудиотекст тыңлыйлар. Текстка карата сорауларга җавап бирәләр. Алга таба укучылар әлеге текстны укыйлар, текст ярдәмендә алдагы дәресләрдә өйрәнелгән материалны ныгыталар.

«Кабатлау» дәресе дә шундый ук структурага ия. Биредә уку материалы сөйләм эшчәнлеге төрләре бүлекләре буенча төзелде: 96 биттә «Кабатлау» дәресендә шигырьне укып, эчтәлеге буенча тест эшләү, төрле биремнәр башкару күз уңында тотыла. «Гомуми кабатлау» дәресе «Куркак юлдаш» әкиятен тыңлаудан башлана, сорауларга җавап бирелә. Төрле кызыклы биремнәр ярдәмендә өйрәнелгән материал искә төшерелә, ныгытыла. База өлешен һәм тирәнтен өйрәнүчеләр өчен эшләнгән күнегүләр ярдәмендә укытучы материалны кабатлата, ныгыта бара.

«Картина белән эш» дәресенең структурасы түбәндәгедән гыйбарәт:

1) Картинаны бергәләп карау. Текстны уку.

2) Сүзлек эшен башкару: *сәке, ыштан, кәтүк, кулдан ясал-*

*ган уенчык, бәрәңге, катык, оекбаш, гөл, тәрәзә төбе, агач кашык.*

3) Сорауларга җавап бирү.
4) План төзү.
5) План ярдәмендә текст төзү.
6) Картинаны кулланып, кечкенә сочинение язу.

## Предметның эчтәлеге

Уку әсбабы дүрт лексик теманы үз эченә ала.

**«Мин»** темасында җәйге ял, авылда, бакчада, диңгездә ял итү турында, мәктәптә уку, яраткан дәресләр, буш вакытны ничек уздыру, шөгыльләр, төрле һөнәрләр, аларның үзенчәлекләре хакында сөйләшү, текстлар белән эшләү, әңгәмәләр кору күз алдында тотыла.

**«Тирә-як, көнкүреш»** темасын өйрәнгәндә, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү өчен, Россиядәге сулыклар, кешеләргә хас сыйфатлар, хайваннар дөньясы, җәнлекләр һәм йорт хайваннары, кошлары, аларның атамалары кебек кечкенә темалар кулланыла.

**«Туган җирем»** темасын өйрәнгәндә, укучылар спорт, аның төрләре, Россиянең күренекле спортчылары, үзебездә үсә торган файдалы үсемлекләр, Россия, аның шәһәрләре, шәһәр парклары, бакчалары, транспорт төрләре, велосипедта йөрү кагыйдәләре, юл билгеләре турында текстлар белән танышалар, әңгәмә коралар. Россия картасын файдаланып, текстлар төзиләр, паркларда, урманнарда, җәмәгать транспортында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән танышалар.

**«Татар дөньясы»** темасында татар милли киемнәре, ризыклары, татарларда кунак сыйлау үзенчәлекләре Шәһри Болгар турындагы текстлар белән эшләп, укучыларның сөйләм теле баетыла.

**Фонетика.** Үзенчәлекле хәрефләр: Әә, Өө, Үү, Җҗ, ң, Һһ. ъ һәм ь хәрефләре. Иҗек. Сүз басымы.

Сүзлекләр белән эшләү. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү.

**Лексика.** Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Антонимнар. Синонимнар. Омонимнар. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр.

Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе.

Текстларда күп мәгънәле сүзләрнең кулланылуы. Сөйләмдә синонимнарны һәм антонимнарны куллану. Омофоннар.

Алынма сүзләр.

**Морфемика.** Сүзләрнең төзелеше һәм ясалышы турында гомуми мәгълүмат. Кушма сүзләр. Парлы сүзләр. Тамырдаш сүзләр. Сүз ясагыч кушымчалар.

Тамыр һәм кушымча. Татар телендә сүзләргә кушымчалар ялгану үзенчәлеге. Кушымчалар ялгап, яңа сүзләр ясау. Форма ясагыч кушымчалар.

**Морфология.** Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. «Кем?», «нәрсә?» сорауларына җавап бирә торган исемнәр.

Зат алмашлыклары.

Сыйфат сүз төркеме.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнүе.

Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнүе.

Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе.

3 зат берлек сандагы хикәя фигыльнең күплек сандагы исемнәр белән кулланылуы.

**Синтаксис.** Сүз, сүзтезмә һәм җөмләне аеру. Җөмләнең баш кисәкләре.

«Нишли?» соравына җавап биргән сүзнең җөмләдәге урыны.

Тиңдәш ияләр. Тиңдәш ияләр янында «һәм» теркәгече (терминны атамый гына), санау интонациясе.

Кереш сүзләр. Аларны сөйләмдә куллану.

**Орфография.** Алфавит. Хәрефләрне дөрес язу. ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.

ъ һәм ь хәрефләре булган сүзләрне юлдан-юлга күчерү.

Кызыл юл.

**Пунктуация.**

Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре. Кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.

# ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәреснең темасы | | Сәг. саны | Белем, эш осталыгы һәм күнекмәләренә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| | Лексик тема | Грамматик тема | | |
| | **МИН**<br>**17 / 8 сәгать** | | | |
| 1 | Без — кояшның дуслары | Алфавит Үзенчәлекле хәрефләр | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Алфавитны яттан белү. Татар теленең үзенчәлекле авазларын дөрес әйтү. Аудиотекстны тыңлау, текст буенча биремнәр эшләү. Сүзләрнең дөрес язылышы. Рәсем буенча текст төзү.<br><br>Исемлек төзегәндә, сүзлекләр, белешмәләр, каталоглар белән эшләгәндә алфавиттан файдалану. Сүзлекләр белән дөрес эшләргә өйрәнү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 6–11, 14–15, 17 битләр. 12–13, 15–16 битләр. |
| | | Сүзлек белән эшләү | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Күп укыган күп белә | ъ һәм ь хәрефләре | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Язуда ъ һәм ь хәрефләрен дөрес куллану. Рәсемнәр белән эшләү.<br><br>Сүзләрне иҗекләргә бүлү. ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне бер юлдан икенчесенә дөрес күчерү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 18, 20–21, 23–25 битләр. 19–20, 21–22 битләр. |
| | | ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне юлдан-юлга күчерү | 1 | |
| 3 | Текст белән эш | | 1 | Дәрестә тыңлаган текст белән эшләү. Телдән һәм язмача төрле күнегүләр эшләү. Өйрәнгән кагыйдәләрне дөрес куллану.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 26–28 битләр. |
| 4 | Буш вакытны файдалы уздыр! | Иҗек | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Сүзләрне юлдан-юлга иҗекләп күчерү | 2 | Сыйныфташың белән диалог төзеп сөйләү.<br><br>Сүзләрне бер юлдан икенчесенә дөрес күчерү. Сүздәге иҗекләр санын билгеләү. Сөйләмдә әдәби тел нормаларын саклау.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 29–30, 32, 34 битләр. 31, 33 битләр. |
| 5 | Сүзлек диктанты | | 1 | |
| 6 | Барлык һөнәр дә яхшы | Сүз басымы | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүз басымын дөрес билгеләү. Басымлы иҗек һәм басымсыз иҗек төшенчәләре белән танышу. Сүзләрдә басымны дөрес куеп уку. Һөнәрләр, билгечлекләр турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Бер иҗекле сүзләр, аларга басым төшу, |
| | | Бер иҗекле сүзләрдә басым | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | кушымчалар ялгану үзенчәлеген белү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 35–40 битләр.<br>38, 39 битләр. |
| 7 | Диктант | | 1 | |
| 8 | Һөнәрләр илендә | Сүзләрне кушып, сызыкча аша һәм аерым язу | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Кушма һәм парлы сүзләрнең ясалу үзенчәлеген белү һәм дөрес язу.<br><br>Текстларны абзацларга бүлү, кызыл юлны дөрес язу.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 41–44, 48–50 битләр.<br>45–47 битләр. |
| | | Кызыл юл | 2 | |
| 9 | Кабатлау | | 1/1 | Аудиотекст белән эшләү. Язмача һәм телдән биремнәр эшләү. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Алдагы дәресләрдә өйрәнгәннәрне кабатлау. Бирелгән план ярдәмендә текстның эчтәлеген сөйләү. |
| **ТИРӘ-ЯК, КӨНКҮРЕШ**<br>**14 / 7 сәгать** | | | | |
| 10 | Атлап чыктым Иделне | Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. |
| | | Татар телендә берничә мәгънә белдерә торган сүзләр | 1 | Сүзләрнең мәгънә төсмерләрен билгеләү. Республиканың сулыклары турында сөйләшү.<br><br>Бер һәм берничә мәгънә белдерә торган сүзләрне билгеләү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 56–58, 60–61 битләр.<br>58–60 битләр. |
| 11 | Берәүнең кулы, икенченең теле эшли | Синонимнар. Антонимнар | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Синонимнарны һәм антонимнарны тану. Сүзләрнең синонимнарын һәм антонимнарын табу. Сорауларга җаваплар бирү. |
| | | Синонимнар һәм антонимнарны сөйләмдә куллану | 1 | Синоним һәм антоним сүзләрнең сөйләмдә кулланылуын күзәтү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 62–54, 68 битләр.<br>65–67 битләр. |
| 12 | Хайваннар дөньясы | Аваздаш сүзләр | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Омонимнарны тану.<br>Диалогик һәм монологик сөйләмне камилләштерү.<br>Җәнлекләрнең һәм йорт хайваннарының атамаларын белү.<br>Укыган текстның мәгънәсен аңлау.<br><br>Омофоннарны белу һәм сөйләмдә тану (терминны атамый гына). Омонимнар белән җөмләләр төзү. Рәсемнәр белән эшләү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 69–74 битләр.<br>71–72 битләр. |
| | | Язылышлары белән генә аерыла торган омоним сүзләр | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13 | Текст белән эш | | 1 | Аудиотекстны тыңлау, аңлау. Телдән һәм язмача күнегүләр эшләү. Дәреслек, 1 кисәк: 75–76 битләр. |
| 14 | Иҗади дәрес | | 1 | |
| 15 | Табигать китабы | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне билгеләү. Текстны үзлектән укып аңлау. Сорауларга җаваплар бирү.<br><br>*-чы/-че* кушымчасы ярдәмендә яңа сүзләр ясау. «Ялкау тиен» текстын уку һәм биремнәр башкару.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 77–83, 85 битләр. 79–80, 81–82, 83–85 битләр. |
| | | *-чы/-че* кушымчасы ярдәмендә яңа сүзләр ясалу | 2 | |
| 16 | Кунак ашы кара-каршы | Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр | 2 | Сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау. Күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне билгеләү. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. |
| | | Лексика | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Диалог төзү. Текст белән эшләү. Татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 86–89, 91–92 битләр.<br>89–91 битләр. |
| 17 | Изложение | | 1 | |
| 18 | Кабатлау | | 1/1 | Алдагы дәресләрдә өйрәнгән лексик һәм грамматик материалны кабатлау. Татар сөйләм этикеты нормаларын үзләштерү.<br>Дәреслек, 1 кисәк: 93–95 битләр. |
| **ТУГАН ҖИРЕМ**<br>**22 / 11 сәгать** | | | | |
| 19 | Спорт белән бик дус без | Сүз төзелеше | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Сүзнең тамырын билгеләү.<br>Укыган текстның эчтәлеге белән эшләү.<br>Табышмаклар чишү.<br>Диалогик һәм монологик сөйләм кору.<br><br>Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә |
| | | Татар телендә сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлекләре | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | кушымчалар ялгау. Спорт турында әңгәмә кору.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 6–10, 12–13 битләр. 10–12 битләр. |
| 20 | Туп тибәм, чана шуам | Тамырдаш сүзләр | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Бер тамырдан ясалган сүзләрне табу. Бирелгән сүзгә тамырдаш сүзләр язу. Таныш лексик материалга корылган текстны үзлектән уку, эчтәлеген аңлау. Тексттан кирәкле мәгълүматны табу.<br><br>Яңа сүз ясый торган һәм яңа сүз ясамый торган кушымчаларны аеру.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 14–15, 18–19 битләр. 16–18 битләр. |
| | | Кушымчаларның төрләре | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21 | Витаминлы аш | Сүз ясагыч кушымчалар | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау. Сүз ясагыч кушымчалардан дөрес файдалану. Табышмакларның җавапларын табу. Дару үләннәре турында әңгәмә кору. |
| | | Сүзнең лексик мәгънәсен һәм формасын үзгәртә торган кушымчалар | 1 | Сүзнең тамырын һәм кушымчаларын билгеләү. Кушымчаның төрен аеру. Текст уку, аның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү. Мәкальләрнең мәгънәсе белән эшләү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 20–24, 25 битләр. 24–25 битләр. |
| 22 | Кабатлау | | 1 | Аудиотекст белән эш. Өйрәнгән лексик һәм грамматик материал белән эшләү.<br><br>Проблемалы ситуацияне чишү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 26–28 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23 | Туган илем буйлап сәяхәт | Кушма сүзләр | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Кушма сүзләрнең ясалу үзенчәлеген белү. Россия шәһәрләренең атамаларын белү. Текст белән эшләү. Сорауларга җавап бирү. Диалог төзү. |
| | | Алынма сүзләр | 1 | Татар телендәге рус алынмаларын тану. Россия картасын карау, аның ярдәмендә текст төзеп сөйләү. Бирелгән модельләр буенча җөмләләр төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 29–30, 33 битләр.<br>31–33 битләр. |
| 24 | Ял паркында | Исемнәрнең килеш белән төрләнүе | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Исем сүз төркемен тану. Килеш категориясе, килеш кушымчалары турында күзаллау булдыру. Килеш кушымчаларының төп мәгънәләрен ачыклау. Паркларда, урманда үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында әңгәмә кору. |
| | | Җанлы предметлар | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Кем? нәрсә? сораула-рына җавап бирә тор-ган исемнәрне аеру. Татар телендә кем? соравының кешегә карата гына кулланы-луын, башка җанлы предметларның нәрсә? соравына җавап бирүен аңлау.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 34–40 битләр. 38, 40–41 битләр. |
| 25 | Текст белән эш | | 1 | Башта тыңлаган, ан-нан соң укыган текст белән эшләү. Өйрәнелгән лексик, грамматик мате-риалны кабатлау. Биремнәр эшләү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 43 бит. |
| 26 | Утырсаң бу транспортка, син китәсең еракка | Зат алмашлык-лары | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Зат алмашлыкларын тану. Тексттан зат ал-машлыкларын табу. Транспорт төрләре турында әңгәмәдә катнашу. |
| | | Зат алмашлык-ларының килеш белән төрләнүе | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Зат алмашлыкларын килешләр белән төрләндерү. Зат алмашлыкларын кабатлаулардан котылу максатында дөрес куллану. Бирелгән модельләр буенча җөмләләр төзү. Су, һава, тимер юл транспортлары турында диалоглар төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 44–47, 51–52 битләр.<br>47–51 битләр. |
| 27 | Иҗади дәрес | | 1 | |
| 28 | Җирдә, күктә, суда кешеләрне йөртә | Фигыльнең берлек санда зат-сан белән төрләнүе | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Фигыль сүз төркемен тану, аның грамматик билгеләрен ачыклау. Хәзерге заман хикәя фигыльләрне берлек санда зат-сан белән төрләндерү. Транспорт атамаларын искә төшерү.<br><br>Кереш сүзләрнең сөйләмдәге ролен аңлау. Алар янында |
| | | Кереш сүзләр | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | тыныш билгеләрен дөрес кую. Юл йөрү кагыйдәләре, җәмәгать транспортында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 53–56, 58–61 битләр.<br>55, 57–58 битләр. |
| 29 | Велосипедта йөри беләсеңме? | Фигыльнең күплек санда зат-сан белән төрләнүе | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Фигыль сүз төркемен тану, аның грамматик билгеләрен ачыклау.<br>Хәзерге заман хикәя фигыльләрне күплек санда зат-сан белән төрләндерү.<br>Юл йөрү кагыйдәләре, велосипедта йөрү кагыйдәләре турында әңгәмә кору.<br><br>3 зат берлек сандагы фигыльләрнең күплек сандагы исемнәр белән кулланылу үзенчәлекләрен белү.<br>Татар сөйләм этикеты |
| | | 3 зат берлек сандагы фигыльләрнең күплек сандагы исемнәр белән кулланылуы | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | үрнәкләреннән дөрес файдалану.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 62–66 битләр.<br>65, 66–67 битләр. |
| 30 | Кабатлау | | 1 | Укыган текстның эчтәлеген аңлау. Текстның темасын, төп фикерен аңлау. Өйрәнгән лексик һәм грамматик материалны кабатлау. |
| **ТАТАР ДӨНЬЯСЫ**<br>**15 / 8 сәгать** | | | | |
| 31 | Кәләпүшем, калфагым | Сыйфат сүз төркеме | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сыйфат сүз төркемен тану. Сыйфатлар кулланып, сүзтезмәләр төзү.<br>Милли уеннар турында әңгәмәдә катнашу. Текстны аңлап уку. Табышмаклар чишү.<br><br>Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсен кулланып, төрле предметларны чагыштыру. Тексттан сыйфатларны табу, |
| | | Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | чагыштыру дәрәҗә-ләрен ясау.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 70–74, 77 битләр.<br>74–77 битләр. |
| 32 | Текст белән эш | | 1 | Текстны үзлектән уку һәм эчтәлеген аңлау. Тексттан кирәкле мәгълүматны эзләү. Җөмләләрдәге хата-ларны табу, аларны төзәтү. Әзер планга нигезләнеп, текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Дәреслек, 2 кисәк: 78–80 битләр. |
| 33 | Кунакка ки-легез! | Җөмләнең баш кисәкләре | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Сүз һәм җөмләне аера белү. Җөмләнең баш кисәкләрен — ия белән хәбәрне табу. |
| | | Татар телендә хәбәрнең җөмләдәге уры-ны | 2 | Баш кисәкләрнең җөмләдәге урынын билгеләү. Татар һәм рус телләрендә җөмлә төзелешен чагыш-тыру. Табын янында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында әңгәмә кору. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Хаталы җөмләләрне төзәтү. Мәкальләрне уку һәм аларның мәгънәләрен аңлату.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 81–83, 85–86 битләр.<br>83–85 битләр. |
| 34 | Картина белән эш | | 1/1 | Картина белән танышканнан соң, әлеге картинаны сурәтли торган текстны уку.<br>Укыган текстка таянып, сорауларга җавап бирү. Картина буенча текст төзеп сөйләү.<br><br>Картинаны игътибар белән караганнан соң, сорауларга җавап бирү. Уку әсбабында бирелгән план ярдәмендә картина буенча текст төзү.<br>План нигезендә сочинение язу.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 87–88 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 35 | Шәһри Болгарга сәяхәт | Җөмлә төзелеше | 4 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аеру (иярчен кисәкләрнең төрен билгеләмичә генә). Сораулар бирү ярдәмендә сүзтезмә, җөмлә эчендәге сүзләр арасындагы бәйләнешләрне билгеләү. Болгар, тыюлык зонасында урнашкан корылмалар турында әңгәмә кору. Кара Пулат турындагы легенданы уку.<br><br>Җөмләләрдә тиндәш иярне билгеләү. Фотографияләр ярдәмендә икмәк музее турында сөйләү. Тиңдәш ияләр кертеп, кечкенә текст төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 89–91, 95 битләр.<br>92–95 битләр. |
| | | Тиңдәш ияләр | 2 | |
| 36 | Изложение | | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 37 | Кабатлау | | 1 | Аудиотекст белән эшләү. Алдагы дәресләрдә өйрәнгән лексик һәм грамматик материалны кабатлау. Татар сөйләм этикеты нормаларыннан дөрес файдалану. Дәреслек, 2 кисәк: 96–97 битләр. |
| 38 | Гомуми кабатлау | | 1/1 | Тыңлаган, укыган текстны аңлау. Фонетика, лексика, грамматика һәм синтаксистан уку елы дәвамында өйрәнелгән материалны кабатлау. Татар сөйләм этикеты нормаларын белү. Дәреслек, 2 кисәк: 98–101 битләр. |

## ДӘРЕС ПЛАННАРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

**Лексик тема: Без кояшның дуслары**
**3 / 1 сәгать**
**1 дәрес**

**Тема: Алфавит**

**Максат һәм бурычлар:** укучыларны быелгы уку елына куелган максат һәм бурычлар, дәреслек һәм аның үзенчәлекләре, шартлы билгеләр белән таныштыру; «Без кояшның дуслары» темасы белән бәйләп, сөйләмә һәм язма телне үстерү; алфавитны яттан белү, татар алфавитындагы хәрефләр санын, аларның урнашу тәртибен, хәреф исемнәрен өйрәтү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Г. Тукайның «Бала белән Күбәләк» шигырен тыңлау.

2) «Бала белән күбәләк» шигыренең эчтәлеге белән эшләү (сораулар һәм җаваплар).

3) Шигырь эчтәлеге ярдәмендә сөйләм төрләрен ачыклау.

4) Алфавитны искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар алфавитындагы хәрефләр саны, аларның урнашу тәртибе, хәреф исемнәре.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Татлы җәй» тексты белән эшләү (6 бит, 2 күнегү).

2) Җәй күчтәнәчләре сурәтләнгән рәсемнәрне кәрзингә җыю (7 бит).

3) «Кояш — безнең дустыбыз» шигырен сәнгатьле итеп уку.

4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

### 2 дәрес

**Тема:** **Татар алфавитындагы үзенчәлекле хәрефләр**

**Максат һәм бурычлар:** «Без кояшның дуслары» темасы белән бәйләп, укучыларның сөйләмә һәм язма телен үстерү; алфавитны яттан белү, алфавит ярдәмендә хәреф һәм авазларны, сузык һәм тартык авазларны искә төшерү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

#### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: татар теленең үзенчәлекле авазлары.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар алфавитындагы үзенчәлекле хәрефләр: ә, ө, ү, җ, ң, һ.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Татар алфавитында гына булган хәрефләрне кертеп, җәй белән бәйле предмет атамалары уйлап язу (10 бит).
2) Рәсемнәрне карау һәм текстларны уку (6 күнегү, 9 бит).
3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
4) Төшеп калган хәрефләрне куеп күчереп язу. Тизәйткечне дөрес итеп кабатлау (7 нче күнегү, 11 бит).
5) Рольләргә бүлеп уку (11 бит).
6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 3 дәрес

## Тема: Татар алфавитындагы тартык авазларны белдерә торган хәрефләр

**Максат һәм бурычлар:** «Без кояшның дуслары» темасына сөйләшүне дәвам итү; татар теленең үзенә генә хас булган хәрефләрне аера белү; алфавит турында мәгълүмат бирү һәм ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: тартык авазларны белдерә торган хәрефләр.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Аваз һәм хәреф санын билгеләү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Текстны уку (8 күнегү, 14 бит).

2) Җөмләләр төзеп әйтү (15 бит).

3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

4) «Әбидә кунакта» тексты белән эшләү (13 күнегү, 17 бит).

5) Берәр хәрефне алыштырып, *көн* сүзен *күлгә* әйләндерү (14 күнегү, 17 бит).

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 4 дәрес

### Тема: Сүзлек белән эшләү алгоритмы

**Максат һәм бурычлар:** «Без кояшның дуслары» темасы турында сөйләшүне дәвам итеп, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; исемлек төзегәндә, сүзлекләр, белешмәләр, каталоглар белән эшләгәндә алфавиттан файдалану; сүзлекләрдән сүзләрне алфавит тәртибендә эзләп табу.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: беренче, икенче, өченче хәрефләре бертөрле булган исемнәрне язу тәртибе.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Сүзлекләрдән сүзләрне алфавит тәртибендә эзләп табу.

**2)** Беренче, икенче, өченче хәрефләре бертөрле булган исемнәрне язу тәртибе.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Диалогларның ахырын уйлау һәм эчтәлеген сөйләү (13 бит).

2) Исемнәрне алфавит тәртибендә язу (10 күнегү, 15 бит).

3) Сүзләрне дөрес урнаштырып, татарча-русча сүзлек төзү (16 бит).

4) Сүзләрне һәм аларның аңлатмаларын дөрес урнаштырып, сүзлек төзү (12 күнегү, 16 бит).

4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

**Лексик тема: Күп укыган күп белә**
**3 / 1 сәгать**

## 5 дәрес

**Тема: ъ һәм ь хәрефләре**

**Максат һәм бурычлар:** «Күп укыган күп белә» темасы турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; ъ һәм ь хәрефләре һәм аларның язылышы турында мәгълүмат бирү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: ъ һәм ь хәрефләренең язылышы.

3) Табышмакның җавабын табу. Табышмак ярдәмендә ъ һәм ь хәрефләренең язылышы турында сөйләшү (16 күнегү, 19 бит).

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) ъ һәм ь хәрефләренең язылышы.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Л. Леронның «Ямьле дөнья!» текстын уку (15 күнегү, 18 бит).

2) «Ямьле дөнья!» текстының эчтәлеге белән эшләү (сораулар һәм җаваплар).

3) «ь» билгесе турындагы экиятне рольләргә бүлеп уку (17 күнегү, 6 бит). Сораулар һәм җаваплар.

4) ъ һәм ь хәрефләренең тиешлесен язу (19 бит).

5) Рольләргә бүлеп уку (20 бит).

6) ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне икегә аерып язу (20 бит).

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 6 дәрес

**Тема: ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы**

**Максат һәм бурычлар:** «Күп укыган күп белә» темасына сөйләшүне дәвам итү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; язуда ъ һәм ь хәрефләрен дөрес куллану.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: язуда ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) ъ һәм ь хәрефләренең дөрес кулланылышы.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Тырыш кыз» шигырен уку (18 күнегү, 21 бит).
2) Шигырь ярдәмендә Тәгъзимә турында сөйләшү (21 бит).
3) Рольләргә бүлеп уку (20 бит).
4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.
7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 7 дәрес

**Тема: Язуда ъ һәм ь хәрефләрен дөрес куллану**

**Максат һәм бурычлар:** «Күп укыган күп белә» темасына сөйләшүне дәвам итү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; язуда ъ һәм ь хәрефләренең дөрес кулланылышын искә төшерү, ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: язуда ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышын искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Рәсемне кара. План ярдәмендә рәсем турында сөйләү (21 күнегү, 23 бит).

2) Рәсемгә карап, текст язу. ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрнең асларына сызу (23 бит).

3) Рәсемне карау. Биремнәрне эшләү (6, 18, 27 саннары өчен булган биремнәр, 24–25 битләр).

4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 8 дәрес

### Тема: ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне юлдан-юлга күчерү

**Максат һәм бурычлар:** «Күп укыган күп белә» темасы турында сөйләшүне дәвам итү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; сүзләрне иҗекләргә бүлү, ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне бер юлдан икенчесенә дөрес күчерү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне бер юлдан икенчесенә дөрес күчерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне юлдан-юлга күчерү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Текстны уку. Сораулар һәм җаваплар (19 күнегү, 21–22 битләр).

2) Текст белән эш. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан-юлга күчерү (22 бит).

3) Күп укыган дустың турында сөйләү (22 бит).

4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 9 дәрес

## Тема: Текст белән эш

**Максат һәм бурычлар:** дәрестә тыңлаган текст белән эшләү; телдән һәм язмача төрле күнегүләр башкару, өйрәнгән кагыйдәләрне дөрес куллану.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: кадерле кунак турында сөйләшү, ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрнең язылышын искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) ъ һәм ь хәрефләре кергән сүзләрне дөрес язу.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Кадерле кунак» текстын уку. Сораулар һәм җаваплар (23 күнегү, 26 бит).

2) Җөмләләрне тулыландыру (26 бит).

3) Төшеп калган хәрефләрне куеп, җөмләләрне күчереп язу (26 бит).

4) Ләйләнең хатын уку (24 күнегү, 27 бит).

5) Биремнәрне эшләү (27 бит).

6) Дядя Фёдор язган хатны уку һәм татарчага тәрҗемә итү (25 күнегү, 28 бит).

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

Учебное издание

**Шакурова** Муслима Магесумовна
**Гиниятуллина** Лилия Миннулловна
**Хисамов** Олег Ришатович

**РОДНОЙ ЯЗЫК**
**(татарский язык)**

3 класс

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования
(для изучающих татарский язык как родной)

*Допущено Министерством образования и науки*
*Республики Татарстан*

Казань. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. 2020
*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Шәкүрова** Мөслимә Мәгъсүм кызы
**Гыйниятуллина** Лилия Миңнулла кызы
**Хисамов** Олег Ришат улы

**ТУГАН ТЕЛ**
**(татар теле)**

3 сыйныф

Методик әсбап
башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән*
*министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән*

Художник *А. Б. Шляпкин*
Верстка *Э. Ф. Нурмухаметовой*

Подписано в печать с оригинал-макета 20.04.2020.
Формат 60 x 84 1/16.